# *Балаларда дизартерия вакытында тавыш коррекциясе*

Укытучы логопед: Мухаметова В.Т.

Сөйләмнең фонетик яктан дөрес булмавы дизартерияның төп билгесе булып тора. Мелодик- интонация дөрес булмаса күп очракта сөйләмнең эмоционаллеге, сәнгатлелеге, аңлаешлылыгының булмавына китерә.

Әгәр дә баланың нормал сөйләшкәндә тавышы яңгырау, көчле, тыңлар өчен җайлы, тавышның темпы яхшы, сулыш алу бозылмаган, сөйләм сулышны чыгарганда әйтелә икән мондый балаларның тавыш халәте дизартерияның стертой формасында бозылган (темп, тавышның көче, модуляция, яңгыравы). Бу балаларның тавышы фраза ахырында карлыгуы табыгый күренеш. Кайбер очракта аңкауның кыскармавы, кече телнең кырыйга тайпылышы күзәтелә, шул тавышның үзгәрүенә сәбәп булып тора. Тавышның нинди булуыннан чыгып- тыныч, көчсез, кырыс, карлыккан, кирәкле коррекцион методика кулланыла.

Тавыш механизмыньң дөрес булмавы йоткылыкның нерв мускуллары аппаратының, беренче очракта тавыш складкаларының хәрәкәтчәнлеге һәм тонуста булуы белән характерлана. Бу тавыш бозылуның гипотонус һәм гипертонус төрләренә бүленә.

**Тавышның гипотонус бозылуы.**

Тавышның гипотонус бозылуы икеяклы миопатик парезның кәефсезләнүенә яки йоткылыкның эчке мускулларының парезы, мускуллар функциясенең кимүенә китерә.

Гипотонус тавыш бозылу вакытында тавыш складкалары тулысынча кысылып бетми, ара кала. Нинди мускул дөрес эшләмәвенә карап формасы ачыклана. Тавышның карлыгуы җиңел формада чагылырга мөмкин. Бу вакытта тавышта арыганлык һәм тамак авыртуы гына түгел, ә мускуллар һәм җилкә дә авырта. Миопатик парез вакытында тавышны куюның максаты – сулыш чыгаруны дөрес итеп җайга салу һәм тавышны көйләүне дөресләү.

**Кайбер күнегүләр.**

1. Борын аша сулыш алырга һәм ыңгырашып борын аша сулышны чыгарырга;

2. Борын аша сулышны алырга һәм әзрәк кенә ачык авыз аша сулышны чыгарырга, йомшак кына тавыш чыгарырга(А);
3. Борын аша сулыш алырга һәм ыңгырашып борын аша сулышны чыгарырга;
4. Борын аша сулыш алырга,  сулышны борын аша әкрен генә чыгарырга, ыңгырашу тавышын башта әкрен генә соңга таба катырак итепчыгарырга;
5. Борын аша сулыш алырга, сулышны ябылып бетмәгән авыз аша ирен-ирен авазын (В) әкрен генә әйтеп чыгарырга;
6. Борын аша сулыш алырга, һаваны авыз аша ыңгырашып вакыт-вакыт суламыйча торып этеп чыгарырга.

Тавышның гипотонус бозылу вакытында еш кына парестезия күзәтелә. Бу вакытта йоткылыкта һәм бугазда нәрсәдер бар шикелле сизелә. Мондый балаларның тавышларының карлыкканын бетерергә кирәк.

Суламыйча, авызны ябып тешләрне әзрәк кенә кысып тавышсыз гынв Ы авазын кабатлау. 2-3 тапкыр.

Муенның алгы өлешен 1-3 минут дәвамында массаң ясарга. Муенның өске өлešеннән башлап аска таба төшергә һәм шул рәвешле тавыш аппаратын көйләргә.  Мондый массажны көнгә 6-7 тапкыр ясарга кирәк.

Муеннын өске өлешенә ясаган мондый массаж тавыш аппаратына кирәкле тон табарга ярдәм итә. Тавышнын дөрес яңгырашы сонор авазларны (М,Н,Л) әйткәндә җиңелрәк  килеп чыга. Бу авазлар бугазны бик көчәндерми.

**Күнегү “ Тавышны битлек аша бирү” яки “Савылмый торган сыер”**

Урындыкка утырырга, үзеңне иркен тотарга кирәк. Тешләрне йозакка ябарга һәм башны күрәккә таба төшерергә. М авазын әйтергә кирәк. Тиешле тонны тапкач борын яфракларына суккаларга мөмкин. Бу вакытта аваз маңгайга менә.

Алга таба аваз иҗекләргә бүленә:

МА-МО-МУ-МЭ-МЫ

НА-НО-НУ-НЭ-НЫ

ЛА-ЛО-ЛУ-ЛЭ-ЛЫ

ВА-ВО-ВУ-ВЭ-ВЫ

ЗА-ЗО-ЗУ-ЗЭ-ЗЫ

ЖА-ЖО-ЖУ-ЖЭ-ЖЫ

Аннары парлы сүзләр китә, басым соңгы иҗеккә төшә:

МАМА/;МАМО/; МАМУ/;МАМЭ/;МАМЫ/

НАНА;НАНО;НАНУ;НАНЭ;НАНЫ

ЛАЛА;ЛАЛО;ЛАЛУ;ЛАЛЭ;ЛАЛЫ

ВАВА;ВАВО;ВАВУ;ВАВЭ;ВАВЫ

ЗАЗА;ЗАЗО;ЗАЗУ;ЗАЗЭ;ЗАЗЫ

ЖАЖА;ЖАЖО;ЖАЖУ;ЖАЖЭ;ЖАЖЫ

Алга таба бер сулышта биш яки җиде иҗекне бергә әйтергә кирәк :

ма_мо_му_мэ_мы

на-но-ну-нэ-ны

ла-ло-лу-лэ-лы

ва-во-ву-вэ-вы

за-зо-зу-зэ-зы

жа-жо-жу-жэ-жы

МАМА-МАМА-МАМАМА;

НАНА-НАНА-НАНАНА

ЛАЛА-ЛАЛО-ЛАЛУ-ЛАЛЭ-ЛАЛЫ

ВАВА-ВАВА-ВАВАВА

ЗАЗА-ЗАЗА-ЗАЗАЗА

ЖАЖА-ЖАЖА-ЖАЖАЖА

Дөрес яңгырашны ныгыту өчен сүзләр әйтә башларга кирәк. Башта басым беренче иҗеккә төшкән сүзләрдән башларга кирәк.

МАМА, МАК, МАЙКА, МАНГО

МОСТ,МОЙЩИК,МОДА,МОЛЬ

МУКА,МУХА,МУЖ,МУЛ

МЕЛ,МЕСЯЦ,МЕТР,МЕБЕЛЬ

МЫЛО,МЫШИ,МЫШЦА,МЫЛЬНИЦА

Алга таба текстлар, шигырләр укый башларга мөмкин.

**Балаларда тавышның гипертонус бозылуы**

Балаларда тавышның гипертонус бозылуы вакытында эчке мускуллар тонуста була. Кайбер очракта йоткылык тулысынча тонуста була. Фонация вакытында тавыш саңгырау булып, басынкы гына чыга. Тавыш тотлыккандагы шикелле паузаларга бүленергә мөмкин. Тавыш складкалары, кыска вакытка кысылып, гиперкениз яки көчәнгән халәттә булалар. Поталогик фонация шулай ук көчәнгән һәм өзлекле фонацион сулыш чыгару белән дәвам итә. Тавыш бозылышын сулыш мускулларының спазмасы китереп чыгара дигән тәэсир калдыра. Сөйләшкәндә иреннәрдә, телдә, яңакларда, муенда таралып китәргә торган шикелле көчәнеш күзәтелә.

Тавышның гипертнус бозылуын дөресләү өчен коррекцион эш түбәндәге эзлеклелектә алып барыла:

1. Сулыш алу коррекциясе һәм фонациядә аның кординациясен торгызу.
2. Тавыш күнекмәләре, һәр бала өчен индивидуаль тавыш тонын формалаштыру.

Тавышның гипертонус бозылуын бетерү өстендә эшләгәндә артикуляцион һәм тавыш аппаратының релакциясе исәпкә алына. Бу спастик тайпылыш булган балалар өчен актуаль.

Гипертонус тавыш бозылганда күнегүләрне тавышка көч бирә торганнардан башларга кирәк.

Мәсәлән: АХ-ОХ-УХ-ЭХ;

Ай,Уй,Эй,Ий;

Ай-яй;Уй-юй;Ой-ей,Эй-ей.

Алга таба фрикатив (Ф,В) иҗекләрне әйтүгә күчәбез. Ф,В авазларының әйтелеше вакытында һава өске иренгә бәрелә.

ФА,ФО,ФУ,ФЭ,ФЫ

ВА,ВО,ВУ,ВЭ,ВЫ

Мондый әйтелеш вакытында иреннәр  һәм бөтен артикуляцон аппарат иркен халәттә була.

Хәрәкәт һәм тавыш күнекмәләрен бергә эшләү тавыш көйләүне җиңеләйтә. Бу максаттан логоритмика куллану уңышлы.

1. Бала өстәл артында логопед каршысында утыра. Логопедның һәм баланың куллары өстәл өстендә.башта логопед күнегүне ничек эшләргә кирәклеген аңлата. Аннары бергәләп синхрон рәвештә сузык авазларны әйтәләр (А,О,У,Э,И)  һәрбер авазны әйткәндә уч табаны белән уң һәм сул кулны чиратлаштырып өстәлгә сугалар. Берничә тапкыр кабатларга кирәк.
2. Башлангыч торыш шул ук. Куллар өстәл өстендә, аннары ике кулның да бер үк  бармаклары бер вакытта өстәлдән алырга һәм сузык авызларны әйтергә кирәк. Баш бармактан башлана – (А), имән бармак-(О), урта бармак-(У), атсыз бармак-(Э), чәнти бармак-(И).  Аннары барысында киредән башлап чәнти бармактан эшлләргә кирәк.
3. Башлангыч торыш шул ук.  Куллар өстәл өстендә.логопед белән бала бергәләп синхронн өстәлгә уч төбе белән суга һәм  басым беренче иҗеккә төшкән сүзләр әйтәләр.

БА-ДА-ГА;

БО-ДО-ГО;

БУ-ДУ-ГУ;

БЭ-ДЭ-ГЭ;

БЫ-ДЫ-ГЫ;

Һәрбер группа өчәр тапкыр кабатлана.

Шул рәвешле теләсә нинди авазны кулланып була, тик тартык аваз яңгырау булуы шарт.  Күнекмәләрдән  соң сузык авазларны логопед артыннан кабатлап барырга мөмкин. Башта авазга һөҗүм ясау аша эшләргә кирәк. Соңыннан алган күнекмәләрне ныгыту өчен иҗекләр һәм сүзләр әйтергә мөмкин. Әкренләп сүзләр, җөмләләр һәм текстлар әйтә башлыйлар.

**Тавышлары бозылган балалар өчен күнегүләр.**

| № | Башлангыч торыш | Тасвирлама | Доза | Методик күрсәтмәләр |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Басып, куллар аста | Гадәттәгечә аяк очларында йөрү; аннары әз генә чүгәләп, янә әкренәеп | 2 минут | Гәүдәне туры тотарга, сулыш иркен |
| 2 | Шул ук | Кулларны ян-яктан өскә күтәрергә, тартылганда сулышалырга кулны аска төшергәндә сулышны чыгарырга | 4 | Темп акрын |
| 3 | Шул ук | Кулларны ян-якка кәтәрергә- сулыш алырга гәүдәне алга ияргә- сулышны чыгарырга; тураерга | 4-5 | Сулыш алу тиз, сулышны чыгарганда Ш авазын әйтергә |
| 4 | Басып, куллар билдә | Гәүдәне төрле якка борырга | Һәр якка 5-6 тапкыр | Темп уртача |
| 5 | Шул ук | Аяк очларына басарга һәм үкчәләргә күтәрелергә | 8-10 | Гәүдәне туры тотарга |
| 6 | Басып. Куллар аста | Сулыш алганда кулларны ян-якка күтәрергә, сулышны чыгарганда аякны күтәреп тез астында кул чабарга. | 4-5 | Темп уртача |
| 7 | Шул ук | Унга сулга иеләбез | Һәр якка 5-6 тапкыр | Темп уртача |
| 8 | Шул ук | Тыныч кына сулыш алырга, | 4-5 | Әкрен генә |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | сулышны чыгарганда ж-ж-жук дип әйтергә | | |
| 9 | Басып, куллар билдә | Тыныч кына сулыш алырга, сулышны чыгарганда кулларны алга сузып утырырга | 5-6 | Темп акрын, сулышны озак итеп чыгарырга |
| 10 | Шул ук | Тезләрне өскә күтәреп бер урында атлыйбыз | 1-2 минут | Сулышны күзәтү |
| 11 | Шул ук | Тезләрне өскә күтәреп бер урында сикерергә | 10-15 | Сулыш алу иркен, темп уртача |
| 12 | Басып, куллар аста | Сулыш алганда кулларны өскә күтәрергә, сулышны чыгарганда гәүдәне алга иергә һәм кулның чукларын селкергә | 5-6 | Темп уртача |
| 13 | Басып, куллар җилкәдә | Терсәкләрне әйләндерергә | 4 тапкыр һәр якка | Сулыш алу иркен |
| 14 | Басып куллар аста | Кулларны хәрәкәтләндереп йөрергә: куллар җилкәдә, ян-якта, аста, өстә, аска төшерергә. | 3-5 минут | Темп акрын, сулыш алу иркен |

**Тавыш югалганда ясала торган сулыш гимнастикасы**

| № | Башлангыч торыш | Аңлатма | Күләме | Методик күрсәтмәләр |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Урындыкка утырып | Авыз аша тиз генә сулыш алырга, | 4-5 | Сулышны бер халәттә тотабыз |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | борын аша чыгарырга | | |
| 2 | Урындыкка утырып куллар тездә | Сулыш алганда кулларны ян-якка җәергә, сулышны чыгарганда куллар тездә | 4-5 | Темп акырын, сулышны авыз аша акрын гына чыгарарсы |
| 3 | Урындыкка утырып, аяклар җилкә киңлегендә | Кулларны өскә күтәреп сулыш алабыз, сулышны чыгарганда алга иелеп бармаклар белән идәнне тотабыз, тураябыз. | 3-4 | Сулышны акрын гына чыгарырга |
| 4 | Урындыкка утырып, куллар күкрәктә терсәктән бөгелгән | Терсәкләрне ике тапкыр артка этәрәбез, кулларны турайтабыз, тезгә куябыз | 5-6 | Сулыш алу ирекле |
| 5 | Урындыкка утырып | Сулышны тиз генә борын аша алабыз, сулышны чыгарганда Ш авазын озын итеп әйтәбез | 5-6 | Муен мускулларын ирекле тотарга |
| 6 | Урындыккам утырып, аркага әзрәк кенә ятып, аяклар | Баәлангыч торышта сулыш алабыз, сулышны чыгарганда аякны | Һәрбер аяк белән 3-4 тапкыр | Темп акырын, сулышны акрын гына чыгарырга |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | туры куллар белән урындык аркасына тотынырга | тездән бөгәбез, турайтабыз тагын бөгәбез, турайтабыз. | | |
| 7 | Урындыкка утырып, куллар аскы кабыргаларда | Сулыш алганда аскы күкрәк читлеген киңәйтәбез, сулышны чыгарганда аскы күкрәк читлеге кысыла | 4-5 | Сулышны акрын гына куллар белән кабыргаларны контролдә тотып чыгарырга |
| 8 | Урындыкка утырып куллар җилкәдә | Уң терсәкне сул тезгә тидерәбез һәм киресенчә | 6-8 | Сулыш алу ирекле |
| 9 | Урындыкка утырып куллар билдә | Сулыш алганда кулларны турайтып ян-якка җибәрәбез, сулышны чыгарганда куллар баш артында гәүдәне ян-якка бөгәбез. | 4-6 тапкыр һәр якка | Сулышны акрын гына авыз аша чыгарабыз |
| 10 | Урындыкка утырып, аркага әзрәк кенә ятып, аяклар туры куллар белән урындык аркасына | Башлангыч торышта сулыш алабыз, сулышны чыгарганда аяклар белән “велосипед” ясыйбыз | 4-5 | Шул ук |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | тотынырга | | | |
| 11 | Урындыкка утырып, куллар тездә | Сулыш алганда кулларны ян-якка турайтабыз, сулышны чыгарганда үз-үзеңне кочаклыйбыз, башлангыч торышка кайтабыз. | 4-5 | Шул ук |
| 12 | Урындыкка утырып куллар билдә | Дүрткә хәтле санап гәүдәне әйләндерәбез | Һәр якка 3 тапкыр | Сулыш алу ирекле |
| 13 | Урындыкка уытырып | Сулышны тиз генә борын аша алабыз, сулышны чыгарганда с авазын озын итеп әйтәбез | 5-6 | Муен мускулларын ирекле тотарга |
| 14 | Урындыкка утырып, куллар билдә | Кулларны ян-якка җибәрәбез- сулыш алабыз, сулышны чыгарганда алга иелеп куллар белән каршы аяк очын тотабыз; башлангыч торышка кайтабыз. | 4-6 тап. Һәр якка | Озак итеп авыз аша чыгарабыз |
| 15 | Урындыкка утырып, аркага әзрәк кенә ятып, аяклар | Кабыргалар һәм корсак белән сулыш алабыз. Сулаганда “Мин сулыш | 1-2 минут | Шул ук |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | турыбер кул күкрәктә, икенче кул белән эчне тотабыз | алганда да сулышны чыгарганда да җиңел итеп сулыйм” | | |

| Күнегүнең эчтәлеге | Күләме | Бер көнгә ничәне ясарга |
|---|---|---|
| Борын аша сулыш алабыз, авыз аша акрын гына сулышны чыгарабыз һәм пауза | 4-5 | 4-5 |
| Өргәндә: 1 адым – сулыш алабыз, 3 адымга – сулышны чыгарабыз, аякларны бергә куябыз- пауза | 4-5 | 4-5 |
| Баскычтан менү: 1 баскыч – сулыш алабыз, икенчесендә сулышны чыгарабыз, аякларны янәшә куеп – пауза. | 1 баскыч | 4-5 |
| Диафрагмаль сулау: сулыш алганда корсакны кабартабыз, сулышны чыгарганда корсак мускулларын әкрен генә эчкә тартабыз. ( күнегү ятып эшләнә) | 1 минут | 5-6 |

**Муен мускулларын һәм бугазның мускулларын ныгыту өчен күнегүләр**. (утырып эшләнелә)

1. Башлангыч торыш- кул замок ясап баш артында. Башны артка этәрәбез, куллар җибәрмичә каршы тора.
2. Башлангыч торыш- йодрыкланган куллар ияк астында. Башны алга иябез, куллар җибәрергә каршы.

3. Башлангыч торыш- уч төпләре колакта. Башларны ян-якка иябез, куллар җибәрергә каршы.
4. Иякне аска, ян-якка, алга хәрәкәтләндерәбез.
5. Яңакларны кабартабыз.
6. Аңкауны өскә күтәрәбез.

**Вокал ярдәмендә башкарыла торган күнегүләр.**

1. Сузык авазны бер сулышта бер нотада өч тапкыр җырлау;
2. Сузык авазны сулышны киң итеп алып терциядә өскә, аска җырлау;
3. Сузык авазвны киң итеп сулыш алып, 5 нота диапозонында өскә күтәреп аска төшереп җырлау;
4. “м”, “н”, “л”, “в”, “з”, “ж” авазларына ачык иҗекләр җырлау;
5. “м”, “н”, “л” авазларына ябык иҗекләр җырлау.

**Тавыш көчен арттыруга күнегүләр.**

1. Күнегүләр шул ук, тик тавышны гамма буйлап аска өскә йөрткәндә, азрак көчәйтеп һәм акрынайтып.
2. Поезд килде-китте  У- у-у-у-у (әкрен генә- кычкырып)
3. Бала елый(а), теш сызлый(М)
4. Тавышның төп тонын күтәрә алу
5. Эт өрә койма астында(гав), песи мияулый койма башында(ч8)
6. КУ-КА-РИ-КУ җырлау Т (53)

Барлык күнегүләрне ясаганда да аңкауны өскә күтәреп тавышны конторольдә тотарга кирәк.

**Балаларда стертой форма дизартрия вакытында тавышның борынлашуы.**

Олылардагы шикелле балаларда да тавыш ясалышында аңкау катнаша. Ул мускуллар белән тәэмин ителгән эластик мембрана булып тора. Бу рецептрларның төп өлкәсе. Аңкауның тавыш ясау функциясе сулау белән бәйле.  Мускулларның ирекле кысылуы рефлектерно бугазның  тавыш яралгыларына  йогынты ясый.  Балаларда стертой форма дизартрия булганда кайбер очракта аңкау тулысынча кыскарып бетми, шуңа күрә тавышның

борынлашуы күзәтелә. Тавышның матур яңгырашын бозучы авыруларга килгәндә, боында оденоитлар үсү, борын раковиналарының зураюы, ринит, борын катары тавышның борынлашуын арттыра гына.

Шулай ук тавышның дөрес, матур яңгырашын борын авырулары, томау төшү, трахеи да комачаулый. Ортодогенные патологиелар да тавышны бозучы булып санала. Кариеслы, черек тешләр миндалиннарның хроник авыруларын китереп чыгара. Шуның өчен балаларга теш табибына вакытында күренеп торырга кирәк.

Борынлашуны бетерү өстендә эшләгәндә ике этап аерылып тора ( Алмазова методикасы)

1. Әзерлек этабы

   А) психотерапия;

   Б) аңкауга, йоткылыкка массаж;

   В) атикуляцион гимнастика;

   Г) сулыш гимнастикасы.

2. Төп этап

   А) югары тавышны үстерү;

   Б) тавыш яңгыравының көче һәм озынлыгы;

   В)тавышның тембрын үстерү;

   Г) җырлы тавыш кую;

   Д)тавышның ритмика-мелодика- сәгатьлелеген үстерү.

Шулай балалар белән логопед эше дә алып барыла. Ул аңкау һәм йоткылыкның арткы стенасы мускулларын активлаштырудан башлана. Бу вакытта логопед практикасында кулланыла торган алымнар кулланыла ( авызны зур итеп ачу, йөткергәләү, тамакны чайкау, чәйнәү, су яки төкерек йоту, атака белән “А”, “Э” сузыкларын әйтү. Аңкауны өскә күтәрү һәм озак вакыт төшермичә торуга күнекмәләр ясау.

**Кулланылган әдәбият.**


1. “Балаларда тавышы кую буенча логопед эше”Е.С.Алмазова.

2. “Балаларда тавышның кимчелекләре”.О.С.Орлова.
3. “Балаларда һәм өлкәннәрдә тавыш һәм сөйләмнең кимчелекләре”В.В.Шиленкова,И.Б.Карелина
4. “Логопедия.Фонопедия нигезләре”.Е.В.Лаврова
5. “Тавышның кимчелекләре”Е.В.Лаврова,О.Д.Коптева,Д.В.Уклонская.